ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МЮД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

КАРАР

№ 3 05.11.2020 ел

«Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлегенең Иске Мукшы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районы «Мюд авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы, Аксубай муниципаль районы, Иске Мукшы авылы, Яшел урамы, 1 нче йорт адресы буенча урнашкан Иске Мукшы авыл клубы бинасы янында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Мукшы авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2021 елда Мюд авыл җирлеге Иске Мукшы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган торучыдан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Иске Мукшы торак пункты чикләрендә вак таш җәелгән юл полотносы урнаштыру (грунтлау, грейдерлау, вак таш җәю, ком сибү, килешү буенча эшләр өчен түләү)
- Иске Мукшы авылы торак пункты чикләрендә кышкы чорда автомобиль юлларын карап тоту (юлларны кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»

3.Әлеге карарны авыл җирлеге халкы күпләп җыела торган урыннарда, стендларда һәм такталарда элеп кую юлы белән, шулай ук Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

ТР Аксубай муниципаль районы
Мюд авыл җирлеге башлыгы Т. В. Зюзина